Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге Башлыгы

# КАРАРЫ

15 ноябрь, 2021 ел

№ 3

## Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Чыты авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 153 номерлы Чыты авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Чыты авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Иске Йорт авылында. 2021 елның 29 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Кооператив урамы, 34 йорт адресы буенча авыл клубы бинасы янында халык җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Иске Йорт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 900 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарын төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Чыты авылында. Халык җыенын дүрт этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2021 елның 30 ноябрендә 08.00 сәгатьтә Кооператив урамы, 85 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет, Чулпан, Болын урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2021 елның 30 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Кооператив урамы, 85 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты

бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Газинур, Зур, Күпер, урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының өченче этабы 2021 елның 30 ноябрендә 12.00 сәгатьтә Кооператив урамы, 85 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Колхоз, Кооператив, Вахитов урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының дүртенче этабы 2021 елның 30 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Кооператив урамы, 85 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Мәктәп, Үзәк, Совет урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Чыты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарын төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чыты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә. Фәйзрахманов